ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**Приказ** **Боерык**

__11.02.2021___ г. Казань № _38-од_____

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 2 июлендәге 162-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетындагы Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында»гы Федераль законның 22 һәм 48 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 27 октябрендәге 346-ФЗ номерлы Федераль законны , «Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә һәм дәүләт органнарының кадрлар резервына кертүгә конкурслар үткәрүнең бердәм методикасына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 24 сентябрендәге 1546 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә боерам:

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәне раслау турында»гы Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 2 июлендәге 162-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.4 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Конкурс комиссиясе составына Комитет рәисе һәм (яки) аның тарафыннан вәкаләтләр бирелгән граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрелә торган Комитетның дәүләт хезмәте һәм кадрлар секторы һәм структур бүлекчәсе (кадрлар резервына кертүгә конкурс үткәрелә торган граждан хезмәте вазыйфалары төркеме буенча һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсе гамәлгә ашырыла торган структур бүлекчә)), Комитет каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, шулай ук бәйсез экспертлар - комитет рәисе соравы буенча Татарстан Республикасы Президенты каршындагы дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә чакырылучы кадрлар технологияләре һәм граждан хезмәте мәсьәләләре буенча тиешле өлкәләрдә һәм һөнәри хезмәт эшчәнлегенең төрләрендә белгечләр булган фәнни, белем бирү һәм башка оешмалар вәкилләре. Бәйсез экспертның Конкурс комиссиясендә булу вакыты өч елдан артмаска тиеш.

Комитет каршындагы Иҗтимагый совет вәкилләренең һәм бәйсез экспертларның гомуми саны Конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итә.»;

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзацлар белән тулыландырырга:

«Конкурс комиссиясе тарафыннан, мондый карарның сәбәбен (нигезләвен) күрсәтеп, аның әгъзасы яисә кандидаты тәкъдиме буенча, утырышны видеоконференция форматында (техник мөмкинлек булганда) үткәрү турында карар кабул ителергә мөмкин.

Комитет тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар тудырыла.»;

абзацы шестой и седьмой пункта 3.4 изложить в следующей редакции:

3.4 пунктының алтынчы һәм җиденче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«нотариаль яки хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте раслаган хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында мәгълүматлар һәм (яисә) гражданның хезмәт эшчәнлеген раслаучы башка документлар (хезмәтэ шчәнлеге беренче тапкыр гамәлгә ашырыла торган очраклардан тыш);

нотариаль яки хезмәт итү урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан расланган, белем бирү һәм квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук граждан теләге буенча өстәмә һөнәри белем бирү нәтиҗәләре буенча квалификация күтәрүне яки тапшыруны раслаучы документлар, гыйльми дәрәҗә бирү турындагы документлар күчермәләре;

4.12 пунктта «бәяли» сүзләреннән соң «һөнәри дәрәҗәсе» сүзләрен өстәргә;

4.12.1 пунктының сигезенче абзацында «10 балл» сүзләреннән соң « минималь балл - 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.12.2 пунктының алтынчы абзацында «10 балл» сүзләреннән соң « минималь балл - 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.12.4 пунктының сигезенче абзацында «10 балл» сүзләреннән соң « минималь балл - 0 балл» сүзләрен өстәргә;

4.13 пунктының икенче абзацында «кандидатлар рейтингын формалаштыра» сүзләреннән соң «аларның йомгаклау балларының кимү тәртибендә» сүзләрен өстәргә.

Рәис Ф.С.Батков